| | | |
|---|---|---|
| ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **КАРАР**<br>**02.10.2020** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1894** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районының хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс-икътисад хезмәте » муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ЗМР БК финанс-икътисади хезмәте» МКУ хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 28 634 |
| Муниципаль учреждение җитәкче урынбасары | 26 986 |
| Бүлек начальнигы | 21 115 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 17 823 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 17 304 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 17 304 |
| Сатып алулар өлкәсендә әйдәп баручы белгеч | 17 304 |
| Әйдәп баручы ревизор | 17 304 |
| Хисапчы | 15 759 |
| План-техник бүлеге белгече | 15 759 |

| | |
|---|---|
| Ревизор | 15 759 |
| Сатып алулар өлкәсендә белгеч | 15 759»; |

1.2. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетларының бухгалтерлык хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) турында нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектә халык саны | Вазыйфаның исеме, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш хисапчы | Хисапчы |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 16 171 | |
| 3,5 меңнән артык кеше | 17 510 | |
| 1,9 меңнән артык кеше | | 14 935»; |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp:/pravotatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин